**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2023 ел № 16

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Азнакай шәһәре территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибе турында» 2019 елның 26 февралендәге 06 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында (14.10.2019 №32 карар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында», 2023 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының «Азнакай шәһәре территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибе турында» 2019 елның 26 февралендәге 06 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру” документына (14.10.2019 №32 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.10 пунктында:

- беренче абзацта «43 статьясындагы 12 өлешендә каралган очракта» сүзләрен «43 статьясындагы 12 өлешендә һәм 45 статьясындагы 22 өлешендә каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

-1 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

-2 һәм 3 пунктчаларын тиешенчә 1 һәм 2 пунктчалары дип санарга.

1.2.12 пунктта «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыздан артык көн» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http//pravo. tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.А. Габдрахманов